Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

12 март 2020 ел № 365

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 3 февралендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында»гы 37 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 3 февралендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында» гы 37 нче номерлы карарына (2013 елның 04 июлендәге 306 нчы номерлы, 2015 елның 13 мартындагы 455 нче номерлы, 2015 елның 10 декабрендәге 40 нчы номерлы, 2017 елның 27 июлендәге 191 нче номерлы, 2018 елның 11 маендагы 240 нчы номерлы, 2019 елның 25 мартындагы 286 нчы номерлы, 2019 елның 25 октябрендәге 330 нчы номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 19 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутат хокуклы түгел:

1) дәүләт хакимияте органнарында һәм җирле үзидарә органнарында башка вазыйфалар биләргә;

2) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

3) коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу, яллаучы вәкиленең Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә яклау;

г) муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (катнашучы) оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен, я муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә яклау;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

4) укытучы, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылар, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә, Россия Федерациясе законнарында яисә чит дәүләтләрнең дәүләт органнары, халыкара яисә чит ил оешмалары белән федераль дәүләт хакимияте органнарының үзара килешүләре нигезендә башкасы каралмаган булса;

5) әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, җирле үзидарә органнарында өченче зат эшләре буенча ышанычлы яисә башка вәкилләр булырга;

6) хезмәт эшчәнлеге өчен генә билгеләнгән мәгълүматны, матди-техник, финанс һәм мәгълүмати тәэмин итү чараларын тиешле булмаган максатларда файдаланырга;

7) Район башлыгы, даими нигездә эшләүче муниципаль вазыйфа башкаручы зат буларак бастырылган язмалар һәм чыгыш ясаган өчен гонорарлар алырга;

8) вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе законнарында каралмаган бүләкләүләр (ссудалар, акчалата һәм башка бүләкләүләр, хезмәтләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү) ,физик һәм юридик затлардан бүләкләр алырга. Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә алынган бүләкләр район милке дип танылa һәм акт буенча тиешле муниципаль органга тапшырыла. Район башлыгы, даими нигездә билгәгән муниципаль вазыйфасына билгән зат беркетмә чарасына, хезмәт командировкасына һәм башка рәсми чарага бәйле рәвештә алган бүләкне Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин;

9) билгеләнгән тәртипкә карамастан, чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм бүтән мактау билгеләрен (фән һәм спорт өлкәләреннән тыш) кабул итәргә;

10) Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган хезмәт командировкаларыннан тыш, Россия Федерациясеннән читкә физик һәм юридик затлар акчалары исәбеннән, район белән чит дәүләтләренең яисә чит дәүләтләренең муниципаль органнары, халыкара яисә чит ил оешмалары белән килешүләр буенча китәргә;

11) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә, Россия Федерациясе законнарында яисә чит дәүләтләрнең дәүләт органнары, халыкара яисә чит ил оешмалары белән дәүләт хакимияте федераль органнарының үзара килешүләр нигезендә башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительлек яисә күзәтү советлары, коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләре составына керергә;

12) хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле булмаган максатларда федераль закон

нигезендә хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа мәгълүм булган чикле мәгълүматтан файдалануга кертелгән белешмәләрне таратырга яисә кулланырга».

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов